МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

№ 121/о

П Р И К А З | Б О Е Р Ы К

"21" 07 2017

"Интернет" мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгындагы Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре һәркемгә ачык мәгълүматны, шулай ук аларны идентификацияләү мөмкинлеген бирә торган мәгълүматларны урнаштырган сайтларның адреслары һәм (яисә) сайтларның битләре турында мәгълүматлар кабул итү, эшкәртү һәм тикшерү тәртибен раслау турында

"Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында" 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 20.2 статьясы, "Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында" 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 17.2 статьясы нигезендә боерык бирәм:

1. "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгындагы Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре һәркемгә ачык мәгълүматны, шулай ук аларны идентификацияләү мөмкинлеген бирә торган мәгълүматларны урнаштырган сайтларның адреслары һәм (яисә) сайтларның битләре турында мәгълүматлар кабул итүнең, эшкәртүнең һәм тикшерүнең кушымтада бирелгән тәртибен расларга.

2. Юридик бүлек башлыгы Э.Ю. Латыйповага дәүләт теркәвенә алу өчен шушы боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек итү секторы җитәкчесе Г.С. Миңнехановага бу боерык Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алынганнан соңгы ун эш көне эчендә аның "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

**Министр** **И.Ә.Фәйзуллин**

ОТДЕЛ ОРГАНИЗАЦИОННО-ПРОТОКОЛЬНОЙ РАБОТЫ, КОНТРОЛЯ И ДЕЛОПРОИЗВОДСТВА

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2017 елның "21 07" №121/0 боерыгы белән расланды

"Интернет" мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгындагы Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре һәркемгә ачык мәгълүматны, шулай ук аларны идентификацияләү мөмкинлеген бирә торган мәгълүматларны урнаштырган сайтларның адреслары һәм (яисә) сайтларның битләре турында мәгълүматлар кабул итү, эшкәртү һәм тикшерү тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгындагы Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре һәркемгә ачык мәгълүматны, шулай ук аларны идентификацияләү мөмкинлеген бирә торган мәгълүматларны урнаштырган сайтларның адреслары һәм (яисә) сайтларның битләре турында мәгълүматлар кабул итү, эшкәртү һәм тикшерү тәртибе (алга таба – Тәртип) түбәндәгеләрне билгели:

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар (алга таба – гражданин) һәм Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгындагы Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре (алга таба, тиешенчә – граждан хезмәткәре, Министрлык) тарафыннан "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә һәркемгә ачык мәгълүмат, шулай ук аларны идентификацияләү мөмкинлеген бирә торган мәгълүматлар урнаштырылган сайтларның адреслары һәм (яисә) сайтларның битләре турында мәгълүматлар (алга таба – Сайтлар турында мәгълүматлар, "Интернет" челтәре) тапшыру кагыйдәләрен;

Сайтлар турында мәгълүматларны кабул итү һәм эшкәртү тәртибен;

Сайтлар турында мәгълүматларның дөреслеген һәм тулы булуын тикшерү тәртибен.

2. Һәркемгә ачык мәгълүмат дигәндә "Мәгълүмат, мәгълүмати технологияләр турында һәм мәгълүматны яклау турында" 2006 елның 27

июлендәге 149-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлеше нигезендә аннан файдалану мөмкинлеге чикләнмәгән, һәркемгә ачык мәгълүматлар һәм бүтән төрле мәгълүмат аңлашыла. Шул ук вакытта мәгълүматтан файдалануда чикләмәнең булмавы затларның чикләнмәгән даирәсенә урнаштырылган мәгълүматны берниндәи каршылыкларсыз алу һәм граждан хезмәткәренең яисә гражданинның рөхсәтеннән башка аннан үзе теләгәнчә файдалану мөмкинлеген бирә.

3. Граждан хезмәткәренең яисә гражданинның шәхесен идентификацияләү мөмкинлеген бирүче мәгълүматлар сыйфатында түбәндәге мәгълүматларның җыелмасы яисә берсе булырга мөмкин: фамилиясе һәм исеме, фотосы, хезмәт урыны.

## II. Сайтлар турында мәгълүматларны кабул итү һәм эшкәртү тәртибе

4. Сайтлар турында мәгълүматларны түбәндәгеләр тапшыра:

гражданин – Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенә (алга таба – граждан хезмәте) керешкәндә граждан хезмәтенә керешкән елдан алдагы өч календарь елы өчен;

граждан хезмәткәре – ел саен, хисап елыннан соң килә торган елның 1 апреленнән дә соңга калмыйча, алдагы календарь елы өчен.

5. Сайтлар турында мәгълүматлар гражданнар һәм граждан хезмәткәрләре тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән Форма (алга таба – Форма) буенча тапшырыла.

6. Һәркемгә ачык мәгълүмат, әгәр дә ул граждан хезмәткәре тарафыннан вазыйфаи бурычларын үтәү кысаларында урнаштырылган булса, Форма буенча чагылдырылырга тиеш түгел.

7. Тутырылган Форма граждан хезмәткәре яисә гражданин тарафыннан дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенең Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы боерыгы нигезендә Сайтлар турында мәгълүматларны эшкәртүне гамәлгә ашыру өчен җаваплы итеп билгеләнгән хезмәткәренә (алга таба – Җаваплы зат) тапшырыла.

8. Җаваплы зат Форманы тутыруның тулы дәрәҗәдә башкарылуын, "Интернет" челтәреннән файдаланып, анда күрсәтелгән мәгълүматларның дөреслеген тикшерә, шәхси имзасын куя, шушы Тәртип Кушымтасына туры китерелгән рәвештә мәгълүматларны Форманы алган көнне журналга кертә.

9. Тутырылмыйча буш урыннары калган Форма кабул ителергә тиеш түгел.

10. Гражданин тапшырган Формада төгәл булмаган мәгълүматлар ачыкланган очракта, дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге ике эш көненнән артмаган чорда аңа граждан хезмәте вазыйфасына билгеләүдән баш тарту турында хәбәр итә.

11. Сайтлар турында мәгълүматлар җаваплы зат тарафыннан граждан хезмәткәрләренең "Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте һәм

Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасы" Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси карточкаларына кертелә.

12. Граждан хезмәткәрләре һәм гражданин тарафыннан тапшырылган Формалар дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегендә биш ел дәвамында саклана, шуннан соң Министрлыкта хезмәткәрләрнең шәхси мәгълүматларын эшкәртү турында нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә юкка чыгарылырга тиеш.

## III. Сайтлар турында мәгълүматларның дөрес һәм тулы булу-булмавын тикшерү тәртибе

13. Граждан хезмәткәрләре тапшырган Сайтлар турындагы мәгълүматларның дөрес һәм тулы булу-булмавын тикшерү Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрының (министр вазыйфаларын башкаручы затның) (алга таба – министр) боерыгы нигезендә гамәлгә ашырыла.

14. Түбәндәгеләр тарафыннан язмача рәвештә тапшырылган, җитәрлек дәрәҗәдәге мәгълүмат тикшерү өчен нигез булып тора:

хокук саклау органнары, бүтән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфаи затлары тарафыннан;

сәяси партияләрнең даими гамәлдә булган җитәкчелек органнары һәм, сәяси партияләр булмаган, закон нигезендә теркәлгән бүтән гомумроссия, төбәкара һәм төбәк иҗтимагый берләшмәләр тарафыннан;

Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы тарафыннан;

гомумроссия һәм республика массакүләм мәгълүмат чаралары тарафыннан.

15. Җаваплы зат язмача рәвештә граждан хезмәткәренә аңа карата тикшерү башлануы хакында тикшерү үткәрү турында боерык чыгарылганнан соңгы ике эш көне эчендә хәбәр итә.

16. Граждан хезмәткәре тарафыннан тапшырылган Сайтлар турында мәгълүматларның дөреслеген һәм тулы булу-булмавын тикшерү җаваплы зат тарафыннан "Интернет" челтәрендә ул урнаштырган һәркемгә ачык мәгълүматны эзләү һәм күрсәтелгән мәгълүматның электрон күчермәләрен (скриншотларын) ясау юлы белән тикшерелә.

17. Граждан хезмәткәре тикшерү барышында һәм аның нәтиҗәләре буенча язмача рәвештә аңлатмалар бирергә, өстәмә материаллар тапшырырга хокуклы.

18. Шушы Тәртипнең 17 пунктында күрсәтелгән аңлатмалар тикшерү материалларына теркәлә.

19. Тикшерү материаллары һәм тикшерү барышында тупланган мәгълүмат министрга тикшерү үткәрү турында боерык чыгарылган көннән башлап 10 эш көненнән артып китмәгән чорда тапшырыла.

20. Тикшерү нәтиҗәләре буенча биш көнлек чорда министр карар кабул итә:

граждан хезмәткәренә карата юридик җаваплылык чараларын куллану өчен нигезләрнең булмавы турында;

граждан хезмәткәренә карата юридик җаваплылык чараларын куллану турында;

тикшерү материалларын, хокук бозу, җинаять, экстремистлык эшчәнлегенә катнашы булу билгеләре булганда, вәкаләтләренә туры китереп, дәүләт органнарына юллау турында.

21. Министр кабул иткән карар турында җаваплы зат язмача рәвештә аңа карата тикшерү үткәрелгән граждан хезмәткәренә ике эш көне эчендә хәбәр итә.

22. Сайтлар турында мәгълүматлар, министрның язмача ризалыгы белән, бер үк вакытта бу хакта аңа карата тикшерү үткәрелгән граждан хезмәткәренә хәбәр итеп, Россия Федерациясенең шәхси мәгълүматлар һәм дәүләт сере турындагы законнарын үтәп, тикшерүне үткәрү өчен нигез булган мәгълүматны җиткерүче хокук саклау органнарына, сәяси партияләрнең даими гамәлдә булган җитәкчелек органнарына һәм, сәяси партияләр булмаган, закон нигезендә теркәлгән бүтән гомумроссия, төбәкара һәм төбәк иҗтимагый берләшмәләренә, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына, гомумроссия һәм республика массакүләм мәгълүмат чараларына тапшырылырга мөмкин.

23. Тикшерү материаллары дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегендә тикшерү тәмамланган көннән соңгы өч ел дәвамында саклана, аннан соң архивка тапшырыла.

## IV. Сайтлар турында мәгълүматлар тапшырмаган өчен җаваплы булу

24. Сайтлар турында мәгълүматлар тапшырмаган очракта гражданин граждан хезмәтенә алына алмый, ә граждан хезмәткәре граждан хезмәтендә була алмый.

25. Граждан хезмәткәренең Сайтлар турында мәгълүматлар тапшырмавы граждан хезмәтеннән куылуга китерә торган хокук бозу булып санала.

"Интернет" мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгындагы Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре һәркемгә ачык мәгълүматны, шулай ук аларны идентификацияләү мөмкинлеген бирә торган мәгълүматларны урнаштырган сайтларның адреслары һәм (яисә) сайтларның битләре турында мәгълүматлар кабул итү, эшкәртү һәм тикшерү тәртибенә кушымта

"Интернет" мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгындагы Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре һәркемгә ачык мәгълүматны, шулай ук аларны идентификацияләү мөмкинлеген бирә торган мәгълүматларны урнаштырган сайтларның адреслары һәм (яисә) сайтларның битләре турында тапшырылган мәгълүматларны исәпкә алу

## ЖУРНАЛЫ

| № п/п | Форманы тапшыру/кабул итү датасы | Форманы тапшыручының ФИА | Форманы тапшыручының вазыйфасы (гражданин дәгъва кыла торган вазыйфа) | Форманы тапшыручының имзасы (яисә, форма почта аша килгәндә, керү №) | Форманы кабул иткән затның ФИА | Рәвешне кабул иткән затның имзасы | Тикшерү турында мәгълүмат (боерык реквизитлары, тикшерү нәтиҗәсе) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |